КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 30 декабрь г.Казань № 1265

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында 1+000 км – 1+300 км участогындагы «Столбище – Атабай» төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын реконструкцияләү максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексының 49 статьясы, VII[1] бүлеге, Россия Федерациясе Граждан кодексының 279 һәм 281 статьялары, Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2011 ел, 21 февраль, 134 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориаль планлаштыру схемасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстанның юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең (алга таба – Татарстанның юл-транспорт идарәсе) Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында 1+000 км – 1+300 км участогындагы «Столбище – Атабай» төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын реконструкцияләү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Столбище авыл җирлеге адресы буенча урнашкан, АК БАРС КАПИТАЛ» идарәче компаниясе җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять идарәсендәге «АК БАРС – Горизонт» ябык пай инвестиция рент фондының (алга таба – алына торган җир кишәрлеге милекчесе) уртак өлеш милкендә булган, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясендәге 6 156 046 кв.метр мәйданлы, 16:24:000000:7149 кадастр номерлы җир кишәрлегеннән барлыкка килә торган 2 908 кв.метр мәйданлы җир кишәрлеген (алга таба – алына торган җир кишәрлеге) алу турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Җир кишәрлегендә урнашкан, кушымтада күрсәтелгән капиталь төзелеш объектлары алынмый дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына түбәндәгеләрне законнар белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә:

10 көн эчендә:

бу карарны үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

бу карарны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районындагы Столбище авыл җирлегенең муниципаль хокукый актларын рәсми бастырып чыгару (халыкка белдерү) өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгаруны;

бу карарның күчермәләрен алына торган җир кишәрлеге милекчесенә, «Роскадастр» гавами-хокукый компаниясенең Татарстан Республикасы буенча филиалына, Татарстанның юл-транспорт идарәсенә җибәрүне;

алына торган җир кишәрлеге өчен түләү күләме билгеләнгәннән соң 30 көн эчендә Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында килешү (алга таба – килешү) әзерләүне һәм аны алына торган җир кишәрлеге милекчесенә җибәрүне;

килешү төзүне;

алына торган җир кишәрлеге өчен акча түләүне;

алына торган җир кишәрлегенә Татарстан Республикасы милке хокукын дәүләт теркәвенә алуны;

алына торган җир кишәрлеге милекчесе тарафыннан имза куелган килешү законнар белән билгеләнгән срокта тапшырылмаган очракта, судка тиешле дәгъва бирүне.

4. Татарстанның юл-транспорт идарәсенә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында 1+000 км – 1+300 км участогындагы «Столбище – Атабай» автомобиль юлын реконструкцияләү» планлаштыру һәм межалау проектын раслау турында» 2021 елның 29 мартындагы 764 номерлы карары белән расланган территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне межалау проекты нигезендә алына торган җир кишәрлегенә карата кадастр эшләрен үткәрүне;

алына торган җир кишәрлеге өчен акча түләү күләмен билгеләүне.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 30 декабрь, 1265 нче
карарына кушымта

Җир кишәрлегендә урнашкан күчемсез мөлкәт объектлары
исемлеге

| Җир кишәрлегенең кадастр номеры | Күчемсез мөлкәт объектының кадастр номеры | Күчемсез мөлкәт объекты исеме |
|---|---|---|
| 16:24:000000:7149 | 16:24:150301:961 | «Альметьевск – Н.Новгород» магистраль нефть продуктлары үткәргеченнән «Татнефтьавиасервис» ябык акционерлар җәмгыятенең ягулык салу комплексына чыгару» ягулык-энергетика, металлургия, химия яисә нефть химиясе производстволарын кору» |
| | 16:24:000000:6617 | «Торбаүткәргеч транспортын кору. Идел буе федераль округы, Столбище авылы, Татарстан Республикасының үзәкләштерелгән архивсаклагычын төзү. Газ белән тәэмин итү системасы» |
| | 16:24:000000:2620 | «Юл транспортын кору. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында «Аэропорт – Столбище» автомобиль юлын реконструкцияләү |